**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 29 апреле** **№18**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2021елның 12 мартындагы-06-2021/9 номерлы протестын карап, карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Красновидово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 24 апрелендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. I бүлекнең 6 пунктындагы 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-калдыкларны саклауны һәм күмүне үз эченә алган калдыкларны урнаштыру, үз чиратында калдыкларны саклау, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү максатларында, унбер айдан артык вакыт эчендә махсуслаштырылган объектларда калдыкларны складлау буларак билгеләнгән..»

III бүлекнең 20 пунктының 2. 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

3. III бүлекнең 20 пунктындагы 4 пунктчасын төшереп калдырырга;

4. III бүлекнең 40.4 пунктында түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: «йорт биләмәләре чикләрендә яшел утыртмаларны тәртиптә тотарга, куакларны һәм агачларны санитар кисеп торырга»;

5. III бүлекнең 40.5 пунктын төшереп калдырырга;

6. III бүлекнең 40.9 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово ав., Совет ур., 4 й.
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк ур., 3 й.

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 29а йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә..

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе И.В.Алешин